КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 декабрь г.Казань № 1201

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 25 август, 610 нчы; 2015 ел, 5 ноябрь, 837 нче; 2015 ел, 5 декабрь, 921 нче; 2016 ел, 22 сентябрь, 673 нче; 2017 ел, 21 февраль, 104 нче; 2017 ел, 24 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 26 июнь, 431 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 767 нче; 2017 ел, 27 декабрь, 1051 нче; 2018 ел, 3 октябрь, 899 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1325 нче; 2019 ел, 6 июнь, 473 нче; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2020 ел, 29 август, 758 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлында:

6 пунктта «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

8 пунктта «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

10 пунктта «2014 – 2020» саннарын «2014 – 2019» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th><th>федераль бюджет</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>3 485 095,5</td><td>391 844,2</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>5 274 816,1</td><td>473 290,5</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>10 424 044,3</td><td>379 869,4</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>8 265 763,1</td><td>445 003,5</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>7 874 476,3</td><td>447 505,6</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>10 234 055,3</td><td>421 227,7</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>10 833 407,66</td><td>562 412,1</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>8 131 724,0</td><td>724 421,1</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>8 657 431,4</td><td>1 077 052,5</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>7 867 108,6</td><td>431 588,3</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>8 842 625,2</td><td>3 840,0</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>8 573 540,9</td><td>3 840,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>98 464 088,36</td><td>5 361 894,9</td></tr>
</table>
Программаны финанслауның гомуми күләме 103 825 983,26 мең сум тәшкил итә, шулардан:
98 464 088,36 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы;
5 361 894,9 мең сумы – җәлеп итәргә күздә тотыла торган федераль бюджет акчасы.
Искәрмә: Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга ел саен, тиешле финанс елына һәм план чорына тиешле дәрәҗәләрдәге бюджетларны формалаштыруны, шулай ук Программа чараларын финанслашуга федераль бюджеттан акча бүлеп бирүне исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш»;
</td>
</tr>
</table>

I бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында үз эшчәнлеген 59 дәүләт мәдәният һәм сәнгать учреждениесе алып бара. Татарстан Республикасы мәдәният объектларының гомуми челтәренә 19 дәүләт һәм муниципаль театр, 19 концерт оешмасы, 173 музей берәмлеге, 1 512 гомумфайдаланудагы китапханә, 1 933 мәдәният-ял итү тибындагы учреждение, 148 кино күрсәтү урыны керә.

Мәдәният үсешенә бүлеп бирелгән шактый акча матди-техник базаны үстерүгә, тармак объектларын төзүгә һәм реконструкцияләүгә, мәдәният учреждениеләре җиһазларын комплексны мәгълүматлаштыруга һәм модернизацияләүгә тотыла.

2020 елгы эпидемиологик хәлгә һәм күпчелек чараларның үткәрелмәвенә карамастан, 2020 елда онлайн хезмәттәшлекнең көчле ресурсы ачыкланды, аның ярдәмендә учреждениеләрнең мәдәни продуктлары (концертлар, спектакльләр, күргәзмәләр) киң аудиториядә файдаланыла һәм сорала башлады. Күп кенә мәдәни чараларны уздыруның яңа концепциясе һәм форматы эшләнде, аларның күбесе интернет-континуумга һәм социаль челтәрләргә күчте. Барлыгы 2020 елда Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләре тарафыннан якынча 58 мең чара онлайн форматта (шул исәптән 523 чара түләүле нигездә) уздырылды, аларда 40 152,0 меңнән артык кеше катнашты. Карантиннан соң театраль-тамаша учреждениеләрендә 4 635,0 мең кеше булды (килеп карау).

Татарстан Республикасы мәдәни мирасны саклап калуга, халыкның белем һәм мәдәни дәрәҗәсен күтәрүгә, патриотизм тәрбияләүгә ярдәм итә торган музей эшчәнлеген үстерүгә зур игътибар бирә. 2020 елда музейларга килүчеләр саны 4 564,920 мең кеше тәшкил итте.

Ел саен Татарстан Республикасы музейларында 100 меңнән артык экскурсия уздырыла, 2,5 меңнән артык музей-күргәзмә проекты гамәлгә ашырыла.

Күргәзмә залларында һәрвакыт рәсем сәнгате, сынлы сәнгать һәм графика, декоратив-гамәли сәнгать, балалар иҗаты күргәзмәләре уздырыла, иҗади остаханәләр, конференцияләр, «түгәрәк өстәл» утырышлары, танылган мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре белән очрашулар оештырыла.

2020 елда театрларда тамашачылар саны 433,0 мең кеше тәшкил итте, 1 692 чара уздырылды.

Татарстанның музыкаль тормышы республиканың академик музыка, этник уен кораллары һәм хореография сәнгате өлкәсендә әйдәп баручы концерт оешмалары һәм иҗат коллективлары эшчәнлегенә таянып алып барыла. Яңа концерт программалары булдыру, фестиваль брендларын үстерү, танылган һәм һөнәри сәнгать дөньясында үзен югары дәрәҗәдә таныткан башкаручылар белән хезмәттәшлек итү – болар барысы да илнең алдынгы музыкаль-мәдәни үзәкләренең берсе буларак республика имиджын ныгытуга ярдәм итә.

2020 елда барлык концерт чараларының тамашачылар саны 253,0 мең кеше тәшкил итте.

Республика китапханәләре күпфункцияле мәдәни үзәкләр буларак үсә, халыкка дистанцион хезмәт күрсәтүләрне үстерү өчен телекоммуникация технологияләре актив үзләштерелә. 2020 елда республика муниципаль районнарында тулаем гомуми файдаланудагы китапханәләр белән тәэмин ителеш 99,2 процент тәшкил итте.

2020 елда китапханә хезмәтләреннән 1 381,617 мең кеше файдаланды. Аларга файдалану өчен 23,3 млн. берәмлектән артык күләмдә саклау фонды тәкъдим ителде.

Гомумфайдаланудагы китапханәләрнең уку йортлары китапханәләре белән, беренче чиратта, мәктәп китапханәләре белән үзара хезмәттәшлеген үстерү эшчән-

лекнең мөһим юнәлеше булып тора. Республика китапханәләре Россиянең башка регионнары китапханәләре белән китапханә арасындагы абонемент һәм китап алмашу системасы аша актив хезмәттәшлек итә.

Татарстан Республикасы кинематографистлары эшчәнлегенең төп юнәлеше – кече шәһәрләрдә һәм авыл торак пунктларында заманча техник чаралар нигезендә кино күрсәтү системасын алга таба камилләштерү, үз илебезнең кинематографын, шул исәптән Татарстан Республикасы кинематографистлары тарафыннан дәүләт заказы буенча төшерелгән фильмнарны пропагандалау. Ел саен 15 меңнән артык киносеанс, шуларның якынча 8,5 меңе балалар өчен үткәрелә, репертуарның яртысын Россия фильмнары тәшкил итә. Мәгариф һәм мәдәният-белем бирү эшчәнлегенең төрле формаларына зур игътибар бирелә.

Казан халыкара мөселман киносы фестивале Татарстанның аерым горурлыгы булып тора, ул беренче көннәрдән үк төрле мәдәният һәм конфессияләр вәкилләре арасында конструктив диалог өчен мәйданчык, күпмилләтле республикабызның визит карточкасы булды.

Ел саен Татарстан Республикасы 63 дән артык зур халыкара фестивальдә катнаша, алар арасында: театр фестивальләре – Ф.И.Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивале, Рудольф Нуриев исемендәге Халыкара классик балет фестивале, төрки халыкларның «Нәүрүз» халыкара театр фестивале, музыкаль фестивальләр – «Филармониада» халыкара фестивале, «Рахлин сезоннары» халыкара фестивале, «Казан көзе» халыкара фестивале, С.Гобәйдуллин исемендәге «Concordia» халыкара заманча музыка фестивале, С.Рахманинов исемендәге «Белая сирень» халыкара фестивале.

Республикада ел саен май аеннан июль аена кадәр халык бәйрәмнәре – «Сабантуй» татар халык бәйрәме, «Каравон» рус фольклор бәйрәме, «Уяв» чуваш мәдәнияте, «Гырон быдтон» удмурт мәдәнияте, «Семык» мари мәдәнияте, «Балтай» мордва мәдәнияте, «Питрау» керәшен мәдәнияте, «Иван Купала» славян мәдәнияте бәйрәмнәре үткәрелә.

Бүгенге көндә халыкның мәдәни ял итүен оештыруда, иҗади мөмкинлекләрен тормышка ашыруда клуб формированиеләре эшенә аерым роль бирелә, 2021 елның 1 гыйнварына мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр каршындагы әлеге формированиеләр саны 15 777 тәшкил итте, аларда катнашучылар 209 569 кеше, шул исәптән авылларда – 13 554 клуб формированиесе, аларда 159 810 кеше шөгыльләнә.

Мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләр килүчеләр белән яңа эшләү формаларын актив кулланышка кертә. Ел саен 347 меңнән артык массакүләм мәдәни чара үткәрелә.

2012 елдан Татарстан Республикасында республика муниципаль районнарының авыл торак пунктларында мәдәни билгеләнештәге объектларны төзү һәм капиталь ремонтлау программалары гамәлгә ашырыла. Барлыгы 2012 елдан 2020 елга кадәр Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 318 күпфункцияле үзәк (авыл клубы) төзелде һәм 233 мәдәни билгеләнештәге объектка капиталь ремонт ясалды.

Шул ук вакытта, мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләрнең матди-техник базасының елдан-ел тузуын исәпкә алып, яңа мәдәният объектларын төзү, мәдәният

учреждениеләрен капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү, заманча җиһазлар белән тәэмин итү эше дәвам ителергә тиеш.

Социологик тикшеренүләр мәгълүматларына караганда, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы мәдәният учреждениеләре челтәре халык ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерми.

Татарстан Республикасының мәдәни киңлегенә чагыштырма анализ ясау республика халкын төрле мәдәният учреждениеләре төрләре белән тәэмин ителү нисбәтен һәм аларга ихтыяҗ рейтингын билгеләргә мөмкинлек бирде.

Халык бәяләвендә тиешенчә тәэмин ителмәү, беренче чиратта, түбәндәге проблемалар белән бәйле:

мәдәният объектларының тигез урнашмавы, эшли торган учреждениеләрнең «файдалану бусагасы» чагыштырмача югары дәрәҗәдә саклану;

мәдәният учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр күләме һәм төрләре гражданнарның ихтыяҗларына, өстенлекләренә һәм өметләренә тулы күләмдә туры килми;

мәдәният учреждениеләрен ял итү һәм иҗади эшчәнлек, мәгариф һәм үзлегеңнән белем алу, чаралар уздыру, һәвәскәр берләшмәләр эшчәнлеге өчен заманча югары технологияле җиһазлар белән, шулай ук халыкның төрле категорияләре, шул исәптән аз мобильле һәм башка тормыш эшчәнлеге өчен мәдәният учреждениеләреннән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү чаралары белән җитәрлек дәрәҗәдә җиһазландырмау;

мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә эшчәнлек башкаручы дәүләткә карамаган структураларның, шул исәптән коммерциягә карамаган оешмаларның мөмкинлекләре җитәрлек дәрәҗәдә файдаланмау, алар белән дәүләт мәдәният учреждениеләре арасындагы үзара хезмәттәшлек формалары үсеш алмау һәм, шуңа бәйле рәвештә, дәүләткә карамаган (иҗтимагый, коммерциягә карамаган, хосусый) оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган мәдәният өлкәсендәге хезмәт күрсәтүләр җитәрлек дәрәҗәдә үсеш алмау;

сәнгатьнең төрле (музыкаль, театр, кино) жанрларында фестиваль һәм башка программалар уздыру, концерт-филармония һәм күргәзмә эшчәнлеге, концерт һәм башка сәнгать коллективлары өчен база сыйфатында файдалану өчен халыкара дәрәҗәдәге зур заманча комплексларга кытлык булу.

Татарстан Республикасы борынгы заманнардан Идел буеның күп кенә халыкларын формалаштыру һәм үстерү тарихын чагылдыра торган, республика һәм гомумроссия күләмендә генә түгел, ә дөнья күләмендә дә кыйммәтле әйберләрне күрсәтә торган уникаль матди һәм матди булмаган мираска ия.

Мәдәни мирас объектларын саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендә дәүләт идарәсен камилләштерү максатларында Татарстан Республикасы Президентының «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты турында» 2018 елның 28 июнендәге ПУ-462 номерлы Указының 3 пунктын үтәү йөзеннән һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 ел, 12 июль, 565 нче карары нигезендә 2018 елда Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты төзелде. Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын

саклау комитеты Татарстан Республикасында Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклап калу, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт саклавы өлкәсендәге йөкләмәләр буенча Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының хокук варисы булып тора.

Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан тарихи һәм мәдәни ядкарьләрне ачыклау һәм өйрәнү эше дәвам ителә.

Дәүләт саклавындагы мәдәни мирас объектларының күпчелек өлеше аларны саклап калу эшләрен үткәрүгә мохтаҗ. Татарстан Республикасы бюджетыннан ремонт-реставрация эшләре башкаруга акча бүлеп бирүдән тыш, һәйкәлләрне саклап калу эшләрен финанслау федераль максатчан программалар аша, шулай ук инвестиция проектларын гамәлгә ашыру юлы белән башкарылырга мөмкин. Әлеге бурычны уңышлы хәл итү өчен, тәкъдим ителә торган объектлар проект-смета документациясе белән тәэмин ителергә тиеш.

Шулай ук гамәлдәге законнар нигезендә мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрен уздыруга проект документациясе дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының уңай бәяләмәсен алырга тиеш.

Мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) саклау чараларын нәтиҗәле гамәлгә ашыру өчен, аларны ремонтлау, реставрацияләү, консервацияләү һәм заманча куллану өчен җайлау, мәгълүмат билгеләре һәм тамгалар урнаштыру белән беррәттән, мониторинг нигезендә алар турындагы мәгълүматларны 2 нче реестрда теркәргә кирәк.

2 нче реестрны документлар белән тәэмин итү максатларында мәдәни мирасның һәр объектына түбәндәгеләр билгеләнергә һәм законнарда билгеләнгән тәртиптә расланырга тиеш:

аларны 2 нче Реестрга кертү өчен нигез булып торган һәм мәҗбүри саклап калу үзенчәлекләре;

мәдәни мирас объекты территориясе чиге һәм аның территориясе чикләрендә җир кишәрлегеннән файдалануның хокукый режимы, һәйкәлне тоту режимы, аны реставрацияләү, консервацияләү, торгызу, ремонтлау һәм җайлау параметрлары;

һәйкәлне саклау зоналары чикләре һәм әлеге зоналар чикләрендә җирләрдән файдалану режимы һәм шәһәр төзелеше регламентлары.

Болар барысы да мәдәни мирасны программа ысуллары белән саклап калу, алардан нәтиҗәле файдалану һәм аларны популярлаштыру проблемалары комплексын хәл итүгә юнәлдерелгән эшне дәвам итү кирәклеге һәм бу эшнең актуальлеге турында сөйли.

Мәдәни мирас объектлары Татарстан Республикасы өчен мөһим әһәмияткә ия, чөнки алар:

тарихи һәм мәдәни үткәннәре бай регион буларак Татарстан Республикасының мәҗбүри атрибуты булып тора;

республика халкы һәм башкала кунаклары яшәү һәм ял итү өчен уңайлы мохитнең мәҗбүри шарты булып тора;

Татарстан Республикасының тарихы һәм гореф-гадәтләренең ачык символлары булып тора;

Россиянең гомумевропа мәдәни контекстына интеграцияләнүен ачык раслау булып тора.

Россия Федерациясе территориясендә күпләп яшәү урыннарында татар халкының тарихи һәм мәдәни истәлекләрен ачыклау һәм өйрәнү, борынгы һәм урта гасыр шәһәрлекләрендә археологик тикшерүләр үткәрү, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары зонасында җимерелә торган аеруча әһәмиятле археологик объектларда саклау-коткару эшләрен дәвам итәргә, фәнни, фәнни-популяр һәм мәгълүмат-белешмә продукциясен әзерләү һәм бастыру эшен дәвам итәргә кирәк.

Хәзерге, кардиналь рәвештә үзгәргән шартларда матди булмаган мәдәни мирасны саклап калу һәм яңадан торгызу иҗтимагый тормышның барлык өлкәләренә актив йогынты ясау һәм тәэсир итү, заманның иң мөһим проблемаларын хәл итү сәләтен югалтмый. Матди булмаган мәдәни мирас балалар һәм яшьләр арасында тискәре социаль күренешләрне профилактикалау һәм җиңеп чыгу, шәхеснең патриотик, гражданлык сыйфатларын формалаштыру, толерантлык, рухилык һәм әхлак тәрбияләү, гаилә һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләрне тотрыкландыру һәм гармонияләштерү чарасы булып тора. Аның ярдәмендә авыл территорияләренең социаль һәм икътисадый потенциалын торгызу һәм үстерү, халыкның мәшгульлеген оештыру, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрнең җайлашуы кебек җитди проблемалар хәл ителә.

Татарстан Республикасында матди булмаган мәдәни мирасны саклап калуның, яңадан торгызуның һәм популярлаштыруның төп проблемалары булып түбәндәгеләр кала: бюджет финанславы җитәрлек булмау, мәдәният учреждениеләренең матди-техник яктан начар тәэмин ителеше, әлеге өлкә белгечләренең минималь акчалата тәэмин ителеше, әлеге тема буенча фәнни тикшеренүләрнең аз санда булуы, белем бирү программаларының тиешле санда булмавы, кадрлар потенциалының җитмәве. Әлеге проблемаларның ведомствоара табигате аларның барлыкка килү сәбәпләренең күптөрлелеге белән аңлатыла һәм аларны, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарын, мәдәният, мәгариф һәм фән учреждениеләрен, иҗтимагый оешмаларны да кертеп, матди булмаган мәдәни кыйммәтләрне саклау һәм тарату процессында төрле катнашучыларны җәлеп итеп, концептуаль һәм программа ысуллары белән хәл итү зарурлыгын китереп чыгара.

Матди булмаган мәдәни мирас өлкәсендә тупланган проблемаларга системалы якын килү башкарма хакимият органнарының, җирле үзидарә органнарының, фәнни-тикшеренү учреждениеләренең, мәгариф учреждениеләренең һәм массакүләм мәгълүмат чараларының әлеге структураларның ярашып эшләве максатларында Татарстан Республикасының матди булмаган мәдәни мирас объектларын саклау, торгызу һәм өйрәнү буенча үзара хезмәттәшлеге регламентын эшләүне күздә тота, бу уңай иҗтимагый фикер булдыруга, үсеп килүче буынны тәрбияләүгә, шулай ук дөнья аренасында Татарстан Республикасының уңай имиджын формалаштыруга ярдәм итәчәк.

Хәзерге вакытта бүгенге көндә дә кулланышта булган, шулай ук соңгы елларда да югалган матди булмаган мәдәни мирас объектларын системалаштыру һәм өйрәнү буенча комплекслы тикшеренүләр юк. Махсуслаштырылган фәнни әдәбияттан гражданнарның абсолют күпчелеге файдалана алмый. XX гасырда басылып чыккан һәм бүгенге көндә нәшер ителә торган Татарстан Республикасы

халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу һәм торгызу проблемасын күпмедер дәрәҗәдә яктырта торган фәнни хезмәтләр, брошюралар, буклетлар сирәк очрый торган библиографик хезмәтләр булып бара, шуңа күрә әлеге эшләрне өстәмәләр кертелгән һәм киңәйтелгән вариантта яңадан бастырып чыгарырга кирәк.

Бүгенге көндә матди булмаган мәдәни мирас объектлары мониторингы мәсьәләсе аеруча кискен тора. Буыннар арасындагы элемтәләр югалу тенденциясе, шулай ук оста әкиятчеләр, йолаларны белүчеләрнең тормыштан китүе күзәтелә. Әлеге процесслар иң әһәмиятле һәм иң борынгы фольклор катламнарының акрынлап сүнүе белән бергә бара. Проблема бик җитди һәм Татарстан Республикасы халыкларының матди булмаган мәдәни мирас объектларын теркәү һәм алга таба саклап калу буенча галимнәр һәм белгечләрнең кичекмәстән һәм максатчан эшен алып баруын таләп итә. Хәзерге шартларда матди булмаган мәдәни мирасның югалган һәм кулланыштагы объектларын, шулай ук локаль традицияләрне йөртүчеләрне ачыклау буенча Татарстан Республикасы районнарына экспедиция сәфәрләре санын арттырырга кирәк.

Матди булмаган мәдәни мирас күренешләре турындагы программаны башлангыч һәм төп белем бирү процессына кертү мәсьәләсе концептуаль, бу программаны тормышка ашыруда кайбер дәүләт карарларын һәм практик адымнар кабул итүгә ярдәм итә торган дәрәҗәдә куелмаган. Мәгарифтә милли сәясәт – ул гомуми милли сәясәтнең бер өлеше, һәм шуның белән бергә ул чагыштырмача мөстәкыйль һәм үзенең махсус дәүләт программасы рәвешендә институциальләштерелгән гыйбарә алырга тиешле нигезенә ия. Мәгариф системасында матди булмаган мәдәни мирасны системалы, максатчан файдалану саллы укыту-методик база булдыруны таләп итә: уку-укыту һәм тикшеренү программаларын, сораулыклар, методик эшләр, уку ярдәмлекләрен эшләү; белгечләрне әзерләү һәм яңадан әзерләү; семинарлар, фәнни-гамәли конференцияләр оештыру.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында һәм аннан читтә халыкларның матди булмаган мәдәни мирасын популярлаштыру буенча мәгълүмат бирү характерындагы сәясәт юк: күргәзмәләр аерымланган характерда оештырыла, бары тик төрле фестивальләрдә, күргәзмәләрдә генә кирәкле фактор булып тора; матди булмаган мәдәни мирас объектлары турында мәгълүмат-белешмә әдәбияты юк диярлек.

Матди булмаган мәдәни мирасны саклап калуга һәм торгызуга йогынты ясый торган факторларны анализлау гамәлдәге проблемаларны локаль традицияләрне йөртүчеләрнең, матди булмаган мәдәни мирасны тикшеренүчеләрнең, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының берләштерелгән көчләре һәм килештерелгән гамәлләре белән хәл итәргә мөмкин булуын күрсәтә. Шул ук вакытта бу процесс дәүләт ярдәменең нәтиҗәлелеге белән билгеләнә, ул матди булмаган мәдәни мирасны саклап калу өчен уңай шартлар тудырырга тиеш.

Матди булмаган мәдәни мирасны саклап калу һәм торгызу эшчәнлеге тәҗрибә-эксперименталь кысалардан чыкты инде. Хәзерге вакытта ул фәнни анализны оештыру, тәэмин итү һәм тупланган тәҗрибәне гомумиләштерү буенча сыйфатлы яңа шартларны, мәдәният һәм мәгариф учреждениеләре эшенә мәдәни традицияләрне

үзләштерүнең һәм гамәлгә кертүнең иң оптималь рәвешләрен һәм ысулларын билгеләүне, җыелган мәгълүмат белән эшләүнең заманча технологияләрен куллануны таләп итә.

Хәзер инде дәүләт структураларын Россиянең милли һәм мәдәни яңарышының көчле үсеш ала торган процессларына кертүнең җитәрлек эпизодик һәм тар колачлы булмавы ачыклана. Халыкның рухи һәм матди мәдәнияте традицияләрен саклап калу һәм торгызу эше программа чараларын һәм ысулларын, нәтиҗәле оештыру һәм финанс ярдәмен куллануны таләп итә. Бары тик җәмгыять белән дәүләт көчләренең махсус оештырылган һәм максатчан процессында берләшү генә мәдәни деградациянең куркыныч зонасын нейтральләштерергә, социомәдәни киңлекнең бөтенлеген торгызырга, этник традицияләр нигезендә чыннан да дәүләт һәм иҗтимагый төзелешнең продуктив төрләрен һәм формаларын эшләргә мөмкинлек бирәчәк.»;

Программаның II бүлегендә:

егерме җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2020 елларга мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә белем бирүне үстерү» ярдәмче программасы мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә һөнәри кадрларны яңадан үстерүнең уникаль системасы буларак, мәктәп – училище – югары уку йорты сәнгать белеменең өч звено системасын камилләштерүгә юнәлтелгән.»;

егерме тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2020 елларга халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү» ярдәмче программасы Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләрен саклап калуга, өйрәнүгә һәм үстерүгә, үсеп килүче яшь буында милли тарихка, традицион халык мәдәниятенә һәм мәдәни мирас өчен горурлыкка хөрмәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән.»;

утыз беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2019 елларга Мирас – Наследие» ярдәмче программасы мәдәни мирасны өйрәнүгә һәм популярлаштыруга, мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) дәүләт тарафыннан саклауны тәэмин итүгә, мәдәни мирасның сакланышын тәэмин итүгә һәм архив фондын тулыландыруга юнәлдерелгән.»;

Программаның III бүлегендәге икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме 103 818 303,26 мең сум тәшкил итә, шулардан: 98 464 088,36 мең сумы – Татарстан Республикасы бюджеты акчасы, 5 354 214,9 мең сумы – җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы.»;

Программага 1, 2, 5 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга музей эшен үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>
1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 8 495 404,0 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 8 495 214,1 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 189,9 мең сум.
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th><th>федераль бюджет</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>531 966,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>539 618,3</td><td>189,9</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>533 321,4</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>599 941,6</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>734 602,7</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>824 559,8</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2020<br>2021</td><td>791 245,5<br>800 404,6</td><td>-<br>-</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>783 828,2</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>806 352,3</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>772 954,5</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>776 419,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>8 495 214,1</td><td>189,9</td></tr>
</table>
Искәрмә: 1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш»;
</td>
</tr>
</table>

1 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Татарстан Республикасының музейлар челтәре Россиядә иң зурларның берсе, ул үз эченә 173 музей челтәре берәмлеген: 68 структур бүлекчәдән торган 14 дәүләт музеен һәм 105 структур бүлекчәдән торган 49 муниципаль музейны ала.

Татарстан Республикасы музейларында 2,1 миллионнан артык саклау берәмлеге саклана, Татарстан Республикасы Музей фондының барлыгы 50 проценттан артыгы Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана.

Музейларга килүчеләрнең төп төркемнәре – гаилә аудиториясе, балалар аудиториясе, яшьләр, килүчеләрнең ташламалы категорияләре (хәрби училищелар курсантлары, хәрби хезмәткәрләр, пенсионерлар, инвалидлар һ.б.). Бүген дәүләт музейлары тарафыннан эшләнә торган төрле программалар һәм акцияләр күпчелек дәрәҗәдә нәкъ менә шушы максатчан төркемнәргә юнәлтелгән.

Музейларга йөрү саны динамикасы, мең кеше




Республика халкының мәдәни кыйммәтләреннән файдалану мөмкинлеге аларда күргәзмәләр оештыру юлы белән генә түгел, ә массакүләм чаралар уздырганда күргәзмәләр, Россия һәм чит ил музейлары белән уртак күргәзмәләр кебек эш формалары белән дә тормышка ашырыла. Музей әйберләрен актив күрсәтүдә катнашкан кешеләрнең чагыштырма авырлыгы 14,6 процент тәшкил итә.

Бүгенге көндә 1,1 миллионнан артык музей предметы электрон каталогка кертелгән. Культуралы кыйммәтләр сакланышын һәм аларны саклау куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен техник чараларны, шул исәптән электрон чараларны кертү һәм алардан файдалану Татарстан Республикасы Музей фондының торышын контрольдә тотуның мөһим инструменты – уңышлы чагыштырып карауның төп факторына әверелә. 2020 ел йомгаклары буенча 80 музейда Татарстан Республикасы Музей фонды әйберләрен саклау шартлары тәэмин ителә, бу республикада музейларның гомуми саныннан 45,9 процент тәшкил итә.

Музей эшенең хәл итүне таләп итә торган проблемалар

Татарстан Республикасы Музей фондын реставрацияләү, консервацияләү җитәрлек дәрәҗәдә үткәрелмәү;

музейларның матди-техник базасының үсеше җитәрлек булмау;

музейларны янгыннан саклау һәм саклау сигнализацияләре, махсуслаштырылган экспозиция-күргәзмә һәм фонд җиһазлары белән тәэмин ителеп бетмәү;

Татарстан Республикасы Музей фондын бөтен килеш мәдәни-мәгариф, фәнни-агарту максатларында актив файдаланмау;

дәүләт музейларын мәгълүматлаштыру җитәрлек дәрәҗәдә булмау;

республика музейлары хезмәткәрләренең уртача яше 50 яшькә якынлаша, бу 5 – 10 елдан тармакта җитди кадрлар кытлыгына китерәчәк;

музейларның фәнни кадрлар белән тәэмин ителешенә кытлык Татарстан Республикасы Музей фондын фәнни өйрәнү, аны фәнни каталоглар, җыентыклар һ.б. бастырып чыгару юлы белән популярлаштыру буенча музейларның актив эшләмәвенә китерә;

инфраструктура үсешенең зәгыйфь булуы аркасында мәдәни туризмны үстерү җитәрлек дәрәҗәдә булмау.

SWOT-анализ

| Көчле яклары | Йомшак яклары |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. Татарстан Республикасы Музей фондының сыйфат һәм дәрәҗәсе.<br>2. Музей белгечләренең югары һөнәри дәрәҗәсе.<br>3. Музей эшендә традициянең дәвамлылыгы.<br>4. Музей төзелмәләрен һәм бүлмәләрен төзү һәм реконструкцияләү.<br>5. Массакүләм мәгълүмат чараларында музейларның эшчәнлеген киң яктырту.<br>6. Бергәләп күргәзмә проектларын оештыру өчен төп федераль музейларны җәлеп итү. | 1. Музейларның матди-техник базасы түбән дәрәҗәдә булу.<br>2. Дәүләт музейларын җитәрлек дәрәҗәдә мәгълүматлаштырмау.<br>3. Медиаресурслардан, аерым алганда, социаль челтәрләрдән нәтиҗәле файдаланмау.<br>4. Яшь белгечләр кытлыгы.<br>5. Музейлар персоналының мотивациясе түбән булу. |
| Мөмкинлекләр | Куркынычлар янау |
| 1. 1 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыруга дәүләт һәм җәмәгатьчелек ярдәме.<br>2. Яңа мәгълүмат системаларын кертү. | 1. 1 нче ярдәмче программаны тулы күләмдә финансламау.<br>2. 1 нче ярдәмче программа белән нәтиҗәле идарә итмәү.<br>3. Административ каршылыклар.<br>4. Реставрация булмау сәбәпле, экспонатларны югалту.»; |

1 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 1 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 8 495 404,0 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 8 495 214,1 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 189,9 мең сум.

| Ел | Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2014 | 531 966,1 | - |
| 2015 | 539 618,3 | 189,9 |
| 2016 | 533 321,4 | - |
| 2017 | 599 941,6 | - |
| 2018 | 734 602,7 | - |
| 2019 | 824 559,8 | - |

| | | |
|---|---|---|
| 2020 | 791 245,5 | - |
| 2021 | 800 404,6 | - |
| 2022 | 783 828,2 | - |
| 2023 | 806 352,3 | - |
| 2024 | 772 954,5 | - |
| 2025 | 776 419,1 | - |
| Барлыгы | 8 495 214,1 | 189,9 |

1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.»;

1 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга театр сәнгатен үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 17 649 798,4 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 17 373 437,5 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 276 360,9 мең сум. |

| Ел | Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2014 | 949 450,2 | - |
| 2015 | 986 742,4 | - |
| 2016 | 966 840,1 | - |
| 2017 | 1 127 814,7 | 33 479,2 |
| 2018 | 1 392 058,2 | 44 212,0 |
| 2019 | 1 571 936,6 | 43 922,2 |
| 2020 | 1 584 390,3 | 79 428,0 |
| 2021 | 1 663 200,6 | 24 737,6 |
| 2022 | 1 772 275,9 | 25 810,0 |
| 2023 | 1 898 545,1 | 24 771,9 |
| 2024 | 1 732 295,8 | - |
| 2025 | 1 727 887,6 | - |
| Барлыгы | 17 373 437,5 | 276 360,9 |

Искәрмә: 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре

| | |
|---|---|
| | фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда төгәенләнергә тиеш»; |

2 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Татарстан Республикасы – Россиянең һәм чит илләрнең танылган профессиональ бергәлегеннән берничә гасырлар дәвамында барлыкка килгән уникаль театр культурасы булган театр үзәкләренең берсе. Татарстан Республикасында театр сәнгатенең мөһим үзенчәлеге бер-берсен баета торган рус һәм татар театр традицияләрен үстерү. Татарстан Республикасының театр пространствосы жанрларның, юнәлешнең һәм иҗат формаларының күптөрлелеге белән аерылып тора. Репертуар театрлары белән беррәттән сәхнә сәнгатенең башка формалары да актив үсә. Дәүләт һәм хосусый театрлар, бердәм театр киңлеген тәшкил итеп, бер-берсе белән гармонияле рәвештә бергә эшлиләр һәм актив хезмәттәшлек итәләр.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елга кадәр иҗтимагый инфраструктура, социаль хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсен билгеләү турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 42 нче карары белән 2024 елга кадәр Татарстан Республикасында инфраструктура, социаль хезмәтләр белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсе билгеләнде.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында 15 дәүләт театры, шул исәптән бер опера һәм балет театры, 10 драма театры, ике яшь тамашачы театры, ике курчак театры эшли:

«М.Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«В.И.Качалов исемендәге Казан академия рус Зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

«Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Казан дәүләт яшь тамашачылар театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Әкият» татар дәүләт курчак театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Әлмәт татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«Габдулла Тукай исемендәге Әтнә татар дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«Т.А.Миңнуллин исемендәге Түбән Кама дәүләт татар драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«Аяз Гыйләҗев исемендәге Яр Чаллы дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«Яр Чаллы дәүләт курчак театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе

«Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә дәүләт татар драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«Буа дәүләт драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«А.В.Баталов исемендәге Бөгелмә дәүләт рус драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе.

Моннан тыш, дүрт муниципаль театр эшли:

Яр Чаллы шәһәренең «Мастеровые» рус драма театры» муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениесе;

«Түбән Кама яшь тамашачы театры» муниципаль бюджет учреждениесе;

«Актаныш муниципаль районының Драма һәм комедия театры» муниципаль бюджет учреждениесе.

Республиканың дәүләт театрларында урыннарның гомуми саны 6 612 утырту урыны тәшкил итә. Ел саен Татарстан Республикасында дәүләт театрлары спектакльләренә 1 миллионнан артык тамашачы йөри. Республикада театр учреждениеләренең гомуми санында дәүләт театрлары өлеше 78 процент тәшкил итә. Чагыштыру өчен, Европаның мәдәни үзәкләрендә бу күрсәткеч: Венада – 62,9 процент, Парижда – 52,7, Берлинда – 44, Лондонда – 13,4, Мәскәү шәһәрендә – 60,2.

Республикада бер мең тамашачыга исәпләнгән театраль креслолар саны 1,7 (Россия буенча уртача – 8,5, Санкт-Петербургта – 5,6, Мәскәүдә – 4,5) тәшкил итә.

Залның республика театрларының стационар мәйданчыгында тулы булуының уртача проценты 85 процент тәшкил итә, бу Россия буенча уртача күрсәткечтән шактый югары (58,1 процент), Санкт-Петербург шәһәрендә, Мәскәү шәһәрендә – 48 һәм 75,3 процент.

Дәүләткә карамаган театр берәмлекләренең булуы театр мохитен булдыруга һәм үстерүгә йогынты ясый. Хосусый театр кысаларында яңа сәнгать чараларын эзләү буенча новаторлык театр төркемнәре үзләрен уңайлы хис итә. Хосусый театрларга дәүләт ярдәме – ул күптөрлелеккә һәм тәҗрибәгә ярдәм итү, аннан башка сәхнә сәнгатен тулы кыйммәтле үстерү мөмкин түгел.

Бүген Татарстан Республикасының театр өлкәсендә дәүләткә карамаган коммерциячел булмаган театр оешмалары үзләре турында ышанычлырак белдерә. Республикада 10 хосусый театр эшли, шуларның иң зур танылганы «Булакта яшьләр театры» (2019 елда ул үзенең 10 еллыгын билгеләп үтте), «Акт театры», «Угол», «Сдвиг» булды. 2020 елда республиканың хосусый театрларында 67,6 мең кеше булды.

Театр учреждениеләре системасының төп күрсәткечләре
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы

| Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең чагыштырма зурлыгы (2020 ел) |
|---|---|
| Биналарның гомуми мәйданы, кв.метр | 98 962 |
| Тамашачылар залларында урыннарның гомуми саны, берәмлек | 6 612 |
| Хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны, кеше | 2 473 |
| Спектакльләр саны, берәмлек | 1 692 |
| Яңа театраль куелышлар саны, берәмлек | 92 |
| Тамашачылар саны, мең кеше | 433 000 |

Татарстан Республикасында төп тамашачыларның ихтыяҗы Татарстан Республикасы дәүләт театрлары тарафыннан канәгатьләндерелә.

Театр эшенең хәл итүне таләп итә торган проблемалары

1. Республика театрлары өчен икътисадның базар моделенә юнәлдерелгән идарәче кадрларны әзерләү зарурлыгы, сирәк театр һөнәрләре белгечләренең квалификациясен күтәрүнең нәтиҗәле системасын үстерү.
2. Театрларны матди-техник һәм финанс белән тәэмин итү.
3. Театр хезмәткәрләрен социаль тәэмин итү.
4. Театр һәм театр тәнкыйте турындагы фәннең җитәрлек дәрәҗәдә үстерелмәве.
5. Дәүләткә карамаган театрларга дәүләт ярдәме кирәклеге.»;

2 ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 2 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 17 649 798,4 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 17 373 437,5 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 276 360,9 мең сум.

| Ел | Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2014 | 949 450,2 | - |
| 2015 | 986 742,4 | - |
| 2016 | 966 840,1 | - |
| 2017 | 1 127 814,7 | 33 479,2 |
| 2018 | 1 392 058,2 | 44 212,0 |
| 2019 | 1 571 936,6 | 43 922,2 |
| 2020 | 1 584 390,3 | 79 428,0 |
| 2021 | 1 663 200,6 | 24 737,6 |
| 2022 | 1 772 275,9 | 25 810,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 2023 | 1 898 545,1 | 24 771,9 |
| 2024 | 1 732 295,8 | - |
| 2025 | 1 727 887,6 | - |
| Барлыгы | 17 373 437,5 | 276 360,9 |

2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.»;

2 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга китапханә эшен үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2 915 557,8 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 871 525,3 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 032,5 мең сум.
<table>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td>Татарстан Республикасы бюджеты</td><td>федераль бюджет</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>179 410,0</td><td>2 719,4</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>176 924,3</td><td>2 668,1</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>189 966,7</td><td>2 909,5</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>202 910,5</td><td>1 497,4</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>241 092,3</td><td>1 621,5</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>262 949,9</td><td>11 768,8</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>284 190,1</td><td>20 847,8</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>251 440,3</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>261 180,6</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>272 430,5</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>274 030,1</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>275 000,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>2 871 525,3</td><td>44 032,5</td></tr>
</table>
Искәрмә: 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

3 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 3 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең
гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Гомумфайдаланудагы китапханәләр бердәм мәгълүмат һәм мәдәни киңлек булдыруда һәм гражданнарның мәгълүмат һәм мәдәни кыйммәтләргә керү хокукларын гамәлгә ашыруда төп звено булып тора.

Татарстан Республикасында 1 511 гомумфайдаланудагы китапханә, шул исәптән дүрт республика китапханәсе (Татарстан Республикасы Милли китапханәсе, Республика яшүсмерләр китапханәсе, Республика балалар китапханәсе, Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе) һәм 1 507 муниципаль китапханә эшли. Республиканың муниципаль китапханәләре 45 үзәкләштерелгән китапханә системасына берләштерелде.

Гомумфайдаланудагы китапханәләр фонды 23,4 миллионнан артык саклау берәмлеген тәшкил итә. Теркәлгән кулланучылар саны – 1,4 млн. кеше (республика халкының 39 проценты, Россия буенча әлеге күрсәткеч уртача 39,4 процент тәшкил итә), ел саен йөрү саны 15,5 млн кешедән артып китә.

Барлык төр һәм типтагы китапханәләр хезмәттәшлегенең төп юнәлешләре булып китапханәара абонемент, фәнни-методик тәэмин итү, уртак программаларны гамәлгә ашыруда катнашу (укуга ярдәм итү һәм пропагандалау, корпоратив мәгълүмат системалары булдыру һ.б.) тора.

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2017 елның 2 августындагы Р-965 номерлы боерыгы нигезендә гамәлгә кертелгән Россия Федерациясе субъектларына һәм җирле үзидарә органнарына мәдәният оешмалары челтәрен үстерү һәм халыкны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү буенча методик тәкъдимнәр нигезендә Татарстан Республикасы гомумфайдалану китапханәләре белән тәэмин ителеш 99,2 процент тәшкил итә. Әмма республика шәһәрләрендә һәм районнарында халык үсеше исәбенә китапханәләр челтәрен арттыру мәсьәләсе килеп баса.

Теркәлгән кулланучылар санының Татарстан Республикасының
гомумфайдаланудагы китапханәләре һәм халык санына карата нисбәте

Китаплар белән тәэмин ителеш Татарстан Республикасының гомумфайдаланудагы китапханәләренә 16,1 китап тәшкил итә (Россия буенча – 16,5 китап).

Республика халкына гомумфайдаланудагы китапханәләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр дәүләт социаль-икътисадый сәясәтенең мөһим факторы булып тора, гражданнарның белеменә һәм мәдәни үсешенә ярдәм итә, республиканың һәр кешесенә мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итә.

2020 ел дәвамында «Цифрлы мохит» ярдәмче проектының «Мәдәният» илкүләм проекты кысаларында Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фондларыннан аерым кыйммәтле һәм сирәк китапларны, шул исәптән тугын якны өйрәнү басмаларын цифрлаштыру эше алып барылды. Проектны гамәлгә ашыра башлаганнан бирле 26,078 мең документ цифрлаштырылды. 2020 елда «Татарстан

Республикасы Милли электрон китапханәсе» порталында 811 документ урнаштырылды һәм 502 яңа кулланучы теркәлде.

Республиканың дәүләт һәм муниципаль китапханәләренә бердәм уку билетын кертү проекты дәвам итә. 2020 ел йомгаклары буенча республиканың 1 411 гомумфайдаланудагы китапханәсе укучыларга бердәм билет буенча хезмәт күрсәтә.

Хәзерге вакытта китапханә тармагында актуаль проблемалар:

1. Китапханәләр фондларын сыйфатлы яңарту темплары акрын бара: актуаль тармак әдәбиятына, балалар әдәбиятына кискен ихтыяҗ бар. Халыкара китапханә ассоциацияләре федерациясе һәм учреждениеләр тәкъдиме буенча гомумфайдаланудагы китапханә фонды ел саен 5 процентка яңартылырга тиеш.

2. Китап саклагычлар өчен мәйданнар җитмәү. Елдан-ел гомумфайдаланудагы китапханәләр биләгән мәйданнар кими. Китапханәләрнең 12 проценты канәгатьләнерлек булмаган биналарда, 25 проценты арендага алынган биналарда урнашкан. Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсен өстәмә мәйданнар белән тәэмин итү мәсьәләсе кискен проблема булып кала.

3. Китапханәләрнең матди-техник базасы зәгыйфь булу – заманча китапханә җиһазлары, транспорт чаралары, фондларның сакланышын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары булмау. Гомумфайдаланудагы китапханәләр физик мөмкинлекләре чикләнгән затларга хезмәт күрсәтү өчен җайлаштырылмаган.

4. Электрон рәвештә күрсәтелә торган хезмәтләрнең күләмен һәм төрләрен арттыру, шул исәптән «Татарстан Республикасының Милли электрон китапханәсе» порталын үстерү таләп ителә, аның кысаларында Татарстан Республикасы китапханәләренең Җыелма электрон каталогы һәм электрон китапханә төзелә. Әлеге бурычны хәл итү өчен китапханәләрнең программа һәм техник комплексларын алга таба мәгълүматлаштыру һәм даими яңартып тору зарури. Программада компьютер җиһазлары һәм программа тәэминаты сатып алу, алга таба гомумфайдаланудагы китапханәләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташтыру, искергән компьютер паркын яңарту күздә тотыла.

Басма документларны башка мәгълүмат йөрткечләргә күчерү эшләре темпларын арттырырга кирәк. 3 нче ярдәмче программалары чараларын гамәлгә ашыру халыкка мәгълүмати-китапханә хезмәте күрсәтүне камилләштерүгә, инновацион технологияләрне үстерүгә, республика халкына мәгълүмати ресурслардан ерактан файдалану мөмкинлеге бирүгә ярдәм итәчәк.

Китапханә фондының куркынычсызлыгын һәм сакланышын тәэмин итү бурычын хәл итү өчен, бәяләр фондларының куркынычсызлыгының комплекслы системасын эшләү һәм гамәлгә кертү, биналарның норматив физик һәм санитария-гигиена торышын саклау, заманча техник иминлек чаралары комплекслары белән тәэмин итү, милли иминият фондын төзү эшләрен дәвам итү зарур.

5. Китапханә кадрларына кытлык проблемасы саклана. Китапханәләрнең профильле белгечләр белән тәэмин ителеше кими. Кадрлар проблемасы яшь белгечләрнең өлеше кимү белән катлаулана.

Һөнәри белем бирү системасын үстерү, шул исәптән заманча укыту ысулларын үстерү, төрле эш формаларын – «түгәрәк өстәлләр», проблемалы семинарларны, һөнәри осталык конкурсларын, тренингларны, эшлекле уеннарны

һ.б. куллану китапханә хезмәткәрләренең квалификациясен тиешле дәрәҗәгә күтәрүгә ярдәм итәчәк.

Китапханә системасын ныгыту, үстерү һәм модернизацияләү буенча бурычларның дәрәҗәсе һәм күләме максатчан программа ысулы нигезендә чишелеш таләп итә. Максатчан программа ысулы 3 нче ярдәмче программада тәкъдим ителгән проблемаларны хәл итүгә ярдәм итәчәк, күрсәтелгән срокларда китапханә эшен үстерү бурычларын комплекслы хәл итәргә булышачак, бу республика халкына китапханә хезмәте күрсәтүнең сыйфатын арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасында китапханә эшен үстерү буенча 3 нче ярдәмче программа Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү буенча дәүләт программасы һәм башка проектлар белән үзара бәйләнештә тора.

SWOT-анализ

| Көчле яклары | Йомшак яклары |
|---|---|
| Үзәкләштерелгән китапханә системаларының үсеш системасы;<br>Республика китапханәләрен «Татарстан Республикасының милли электрон китапханәсе» порталы кысаларында бердәм мәгълүмат системасына интеграцияләү | Тармакны финанс белән тәэмин итеп бетермәү;<br>кадрлар потенциалы кимү;<br>җиһазларның шактый өлеше искерү, китапханә биналарының заманча дизайн һәм уңайлы мохит таләпләренә туры килмәве |
| Мөмкинлекләр | Куркынычлар янау |
| Мәгълүмат технологияләрен үстерү ярдәмендә китапханә ресурсларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдалану мөмкинлеген арттыру;<br>кызыксынучы учреждениеләр, оешмалар, шул исәптән Россия Федерациясенең башка регионнары һәм чит илләр белән хезмәттәшлек һәм стратегик партнерлыкны үстерү;<br>менеджментны камилләштерү;<br>китапханәдә хезмәт күрсәтүнең яңа формаларын ачыклау һәм гамәлгә кертү, шул исәптән сервис мөмкинлекләрен киңәйтү;<br>китапханәне аралашу һәм иҗат итү урыны буларак үстерү;<br>проект эшчәнлеген үстерү, грантларда, конкурсларда, проектларда китапханәләр катнашу | Халыкның кызыксынуы өстенлекләре үзгәрү: укучылар саны кимү;<br>кадрлар потенциалын киметү, квалификацияле белгечләр китү;<br>фондларның сакланышы түбән дәрәҗәдә булу»; |

3 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 3 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

3 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 2 915 557,8 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 871 525,3 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 44 032,5 мең сум.

| Ел | Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2014 | 179 410,0 | 2 719,4 |
| 2015 | 176 924,3 | 2 668,1 |
| 2016 | 189 966,7 | 2 909,5 |
| 2017 | 202 910,5 | 1 497,4 |
| 2018 | 241 092,3 | 1 621,5 |
| 2019 | 262 949,9 | 11 768,8 |
| 2020 | 284 190,1 | 20 847,8 |
| 2021 | 251 440,3 | - |
| 2022 | 261 180,6 | - |
| 2023 | 272 430,5 | - |
| 2024 | 274 030,1 | - |
| 2025 | 275 000,0 | - |
| Барлыгы | 2 871 525,3 | 44 032,5 |

3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.»;

3 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга концерт оешмаларын һәм башкару сәнгатен үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 4 нче ярдәмче программа):

4 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 8 923 179,0 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 8 915 279,0 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 7 900,0 мең сум. |

| Ел | Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджеты | федераль бюджет |
| 2014 | 567 780,8 | - |
| 2015 | 564 844,5 | - |
| 2016 | 528 674,6 | 7 900,0 |
| 2017 | 669 792,6 | - |
| 2018 | 749 270,2 | - |
| 2019 | 855 235,6 | - |
| 2020 | 780 319,4 | - |
| 2021 | 782 823,4 | - |
| 2022 | 818 472,7 | - |
| 2023 | 860 148,1 | - |
| 2024 | 868 587,8 | - |
| 2025 | 869 329,3 | - |
| Барлыгы | 8 915 279,0 | 7 900,0 |

Искәрмә: 4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш»;

4 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Татарстан Республикасында җиде дәүләт концерт оешмасы эшли:

«Салих Сәйдәшев исемендәге Дәүләт Зур концертлар залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе (Татарстан Республикасы Дәүләт камера хорын үз эченә ала),

«Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе (аңа Татарстан Республикасының рус халык уен кораллары дәүләт оркестры, Татарстан Республикасының Дәүләт фольклор музыка ансамбле, Татарстан Республикасының Филармония джаз-оркестры, Филармония музыкаль-әдәби лектория керә),

«Татарстан Республикасының Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе,

«Татарстан Республикасы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе,

«Бермәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе,

«Мизгел» бию театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе,

«Агыйдел» җыр һәм бию ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе.

Дәүләтнекеннән тыш, республикада 12 муниципаль концерт оешмасы эшли:

«Казан» милли мәдәни үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе;

«Ля Примавера Казан камера оркестры» Казан шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«София Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе;

«Орган залы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«Болгар» бию театры» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«Игорь Лерман камера оркестры» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе

«Сара Садыйкова исемендәге Концертлар залы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«Визит» джаз оркестры» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«Түбән Кама шәһәренең концерт-иҗат үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәренең «Нардуган» җыр һәм бию ансамбле» муниципаль бюджет учреждениесе;

«Түбән Кама шәһәренең «Илһам» татар эстрада ансамбле» муниципаль бюджет учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт» милли-мәдәни үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының
концерт оешмалары һәм коллективлар системасының төп күрсәткечләре

| Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең чагыштырма зурлыгы (2019 ел өчен) |
|---|---|
| Тамашачылар залларында урыннарның гомуми саны, берәмлек | 3 287 |
| Биналарның гомуми мәйданы, кв.метр | 19 200,3 |
| Хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны, кеше | 1 151,1 |
| Концертлар саны, берәмлек | 1 818 |
| Тамашачылар саны, мең кеше | 253 000 |

2020 елда Татарстан Республикасының концерт оешмаларында 1,8 меңнән артык концерт үткәрелде. Татарстан Республикасында концерт программаларында 253,0 мең тамашачы катнашты.

Татарстан Республикасында 2020 елда концерт абонементын үстерү эш дәвам ителде. Концерт практикасының мондый формасы республика халкының төрле катламнары өчен елдан-ел популярлаша һәм һәркем аннан файдалана ала, музыкаль сәнгатьне яратучылар саны, шул исәптән балалар һәм яшьләр арасында арта. А.Сладковский җитәкчелегендәге «Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесенең абонемент концертлары П.И.Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясенең Зур залы эше планына кертелә.

Концерт оешмалары эшчәнлеге проблемалары:

дөньякүләм югары стандартларга туры килә торган акустик үзлекләргә ия филармония мәйданчыкларының саны җитәрлек булмау;

кайбер стационар концерт мәйданчыклары җитәрлек дәрәҗәдә нәтиҗәле булмау;

кайбер филармония чараларына йөрү җитәрлек дәрәҗәдә югары булмау;

үз иҗади-репетиция базасына ия булмаган берничә музыкаль коллективның бер үк вакытта урнашуы һәм эшләве өчен кирәкле репетиция заллары һәм хезмәт бүлмәләре җитәрлек булмау.

Концерт эшчәнлегенә дәүләт ярдәменең төп юнәлешләре:

филармония һәм фольклор эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтү;

балаларга һәм үсмерләргә абонемент хезмәте күрсәтүне киңәйтү;

яшьләр конкурслары һәм фестивальләр уздыру юлы белән музыкаль классик сәнгать өлкәсендә төрле һөнәр ияләренең иң талантлы яшь вәкилләренә ярдәм итү;

республика өчен социаль әһәмиятле яңа филармония һәм фольклор иҗади проектларга грант ярдәме күрсәтү.»;

4 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 4 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

4 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 8 923 179,0 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 8 915 279,0 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 7 900,0 мең сум.

| Ел | Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Татарстан | федераль бюджет |
| 2014 | 567 780,8 | - |
| 2015 | 564 844,5 | - |
| 2016 | 528 674,6 | 7 900,0 |
| 2017 | 669 792,6 | - |
| 2018 | 749 270,2 | - |
| 2019 | 855 235,6 | - |
| 2020 | 780 319,4 | - |
| 2021 | 782 823,4 | - |
| 2022 | 818 472,7 | - |

| | | |
|---|---|---|
| 2023 | 860 148,1 | - |
| 2024 | 868 587,8 | - |
| 2025 | 869 329,3 | - |
| Барлыгы | 8 915 279,0 | 7 900,0 |

4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.»;

4 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга кинематографияне саклап калу һәм үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа):

5 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән<br>743 844,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 ел – 64 811,9 мең сум;<br>2015 ел – 67 977,6 мең сум;<br>2016 ел – 54 602,5 мең сум;<br>2017 ел – 84 096,8 мең сум;<br>2018 ел – 54 485,5 мең сум;<br>2019 ел – 77 083,0 мең сум;<br>2020 ел – 45 420,0 мең сум;<br>2021 ел – 56 614,9 мең сум;<br>2022 ел – 58 107,8 мең сум;<br>2023 ел – 59 804,4 мең сум;<br>2024 ел – 59 571,8 мең сум;<br>2025 ел – 61 268,4 мең сум.<br>Искәрмә: 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш»; |

5 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 5 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль кинематография учреждениеләре, кинога хезмәт күрсәтүнең социаль гарантияләнгән төрләренә

хокукны халыкның төрле категорияләренә тәэмин итеп, мөһим функцияләр башкара.

Татарстан киночелтәре 159 кинокүрсәтү ноктасыннан тора, шуларның берсе дәүләт киноучреждениесе – «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе (өч кино залы), 7 муниципаль кинотеатр (сигез кинозал) һәм 25 хосусый кинотеатр (123 кино залы), мәдәният-ял итү учреждениеләрендә 40 муниципаль кино залы. Шулай ук даими рәвештә кино, видео хезмәте күрсәтә торган 27 күчмә кино күрсәтү аппараты бар.

2015 елдан 2019 елга кадәр Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы һәм федераль Кино фондының халык саны 100 меңгә кадәр һәм 500 мең кешегә кадәр торак пунктларда милли фильмнар күрсәтү өчен шартлар тудыру проекты кысаларында шәһәрләрдә һәм район үзәкләрендә 28 кино залы федераль акчага яңа цифрлы җиһаз белән җиһазландырылды.

2020 елда 2019 елның дәүләт заказы буенча төрле жанрдагы сигез фильм булдырылган: дүрт документаль, ике уен, ике анимацион. Шулай ук 2018 елгы дәүләт заказының дүрт фильмы төшереп бетерелде.

«Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе Татарстанның мәдәни тормышында мөһим роль уйный. Сәнгать һәм документаль фильмнарның (телсез кино чорының кинокартиналарыннан алып хәзерге яңаларына кадәр) зур фондына ия булып, учреждение коллективы халыкның мәдәни ялын оештыру буенча, шулай ук эстетик, идея-әхлакый, патриотик тәрбияләү буенча зур эш башкара. Республиканың бер генә истәлекле вакыйгасында кинофильмнар кулланмыйча уздырылмый.

Татарстан Республикасында 40 кинотеатр һәм киноүзәк эшли, шуларның 17се – Татарстан Республикасы милкендә, 23 се – дәүләтнеке булмаган милек формасында. Әлеге санга гамәлдәге кинотеатрлар һәм киноүзәкләр дә, төрле сәбәпләр аркасында кинокүрсәтүләрне гамәлгә ашырмаган кайбер кинотеатрлар да керә. Нигездә, бу төзекләндерүне һәм капиталь ремонтлауны таләп итә торган, торышы канәгатьләнерлек булмаган дәүләт кинотеатрлары, шулай ук элек коммерция арендасына тапшырылган, яңадан изоляцияләнгән һәм үзләренең функциональ билгеләнешен үзгәрткән дәүләт кинотеатрлары. Җитди финанс чыгымнары белән торгызуны таләп итә торган, кулланылмый торган кинотеатрлар базасында дәүләт-хосусый партнерлык кысаларында инвестиция проектлары гамәлгә ашырылачак.

Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль киноучреждениеләре эшчәнлегенең хәл итүне таләп итә торган проблемалары:

1. Татарстан Республикасында кино хезмәте күрсәтү һәм кинопроизводствоның заманча дөнья стандартларыннан сизелерлек артта калуы;

2. Искергән кинотехнологик җиһазлар;

3. Югары иҗади звеноның квалификацияле кадрлары җитешмәү;

4. Кино җитештерүгә һәм кинотармакның матди-техник базасына җитәрлек дәрәҗәдә дәүләт ярдәме күрсәтелмәү.»;

5 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 5 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

5 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 743 844,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2014 ел – 64 811,9 мең сум;
2015 ел – 67 977,6 мең сум;
2016 ел – 54 602,5 мең сум;
2017 ел – 84 096,8 мең сум;
2018 ел – 54 485,5 мең сум;
2019 ел – 77 083,0 мең сум;
2020 ел – 45 420,0 мең сум;
2021 ел – 56 614,9 мең сум;
2022 ел – 58 107,8 мең сум;
2023 ел – 59 804,4 мең сум;
2024 ел – 59 571,8 мең сум;
2025 ел – 61 268,4 мең сум.

5 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.»;

5 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә мәгарифне үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа):

исемендә «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

6 нчы ярдәмче программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

«6 нчы ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары» юлында «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» һәм «Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программа максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 6 нчы ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 344 436,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 ел – 328 570,6 мең сум;<br>2015 ел – 4 006,9 мең сум;<br>2016 ел – 2 896,9 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2017 ел – 3 030,3 мең сум;<br>2018 ел – 2 836,4 мең сум;<br>2019 ел – 1 752,8 мең сум;<br>2020 ел – 1 342,9 мең сум.<br><br>Искәрмә: 6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш |
| «Еллар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаның максатын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | 6 нчы ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә укучылар контингентын 100 процентка кадәр саклау;<br>түбәндәгеләрне арттыру:<br>өстәмә белем бирү учреждениеләре укучыларының гомуми санында фестиваль-конкурс хәрәкәте белән колачланган укучылар өлешен (шәһәр, төбәк, бөтенроссия, халыкара чараларда катнашу) 75 процентка кадәр;<br>сәләтле балалар өчен иҗади чаралар санын 16 берәмлеккә кадәр;<br>уздырылган мастер-класслар, семинарлар, конференцияләр саны 12 берәмлеккә кадәр»; |

6 нчы ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 6 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Безнең илдә барлыкка килгән уникаль сәнгать белеме системасының 125 еллык тарихы бар. Сәнгать өлкәсендә Россия һөнәри белем бирү системасының төп принцибы – «мәктәп – училище – югары уку йорты» өч звено белем бирү процессының дәвамчанлыгы һәм өзлексез булуы.

Сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерләү кайбер үзенчәлекләргә ия:

һөнәри белем бирү оешмаларына һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларына кабул итү, кагыйдә буларак, һөнәри белем бирүнең алдагы баскычын күздә тотучы һөнәри сайлап алу (иҗади сынаулар) нигезендә гамәлгә ашырыла;

музыка, рәсем сәнгате, хореография сәнгатендә һөнәри белем бирү балалар яшендә башлана, аерым алганда, кайбер укыту программалары алты яшьтән тугыз яшькә кадәр укый башлауны күздә тота;

уку процессы башлыча индивидуаль дәресләргә һәм укытуның аз төркемле формаларына юнәлдерелгән;

уку йортларының иҗади оешмалар белән үзара тыгыз бәйләнештә тора, уку процессында сәнгать һәм мәдәният эшлеклеләре турыдан-туры катнаша;

һөнәргә ия булу көн саен күп сәгатьлек дәресләр таләп итә, шуңа күрә укучыларның атналык гомуми йөкләнеше (мөстәкыйль дәресләрне исәпкә алып) еш кына 54 сәгатьлек нормадан артып китә.

Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә илебез мәгариф системасы эшчәнлегенең мөһим шарты булып балаларга сәнгать-эстетик белем бирүнең (балалар музыка, сәнгать мәктәпләре, сәнгать мәктәпләре) һәркем өчен ачык булуы һәм массакүләм характеры тора, ул традицион рәвештә киң эстетик белем бирү һәм тәрбия функцияләрен үти генә түгел, ә талантны иртә ачыклау һәм аның алга таба һөнәри формалашуы өчен шартлар тудыру да тора.

Шулай итеп, балалар сәнгать мәктәпләре сәнгать белеменең мөһим башлангыч этабы булып тора, ул грамоталы тыңлаучыларны, тамашачыларны, эстетик яктан әзерләнгән «мәдәниятне кулланучыларны» гына түгел, ә булачак профессионалларны тәрбияли.

Мондый төрдәге уку йортлары Россиядә XIX гасырның икенче яртысында беренче рус консерваторияләре (Мәскәү һәм Санкт-Петербург) һәм Сәнгать академиясе каршында башлангыч уку баскычлары буларак оештырылган була. Нәкъ менә шуңа күрә балалар сәнгать мәктәпләрендә белем бирү эчтәлеге ике сыйфат белән билгеләнә: предметларны комплекслы укыту һәм белем бирүнең ике дәрәҗәсе булу: массакүләм (гомумэстетик) һәм башлангыч һөнәри белем бирү аша сәнгать төрләрен үзләштерү.

Хәзерге вакытта республикада мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә кадрлар әзерли торган 116 мәгариф оешмасы челтәре эшли:

105 өстәмә белем бирү оешмасы;

тугыз һөнәри белем бирү оешмасы;

югары белем бирә торган ике мәгариф оешмасы.

2020 елның 1 декабренә мәдәният һәм сәнгать мәгариф оешмаларында белем алучылар саны 43 591 кеше тәшкил итте, шуларның:

36 827 кеше балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында белем ала, шулардан 420 кеше – «Бәхетле балачак» балалар үзәге» өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесендә;

2 566 кеше – һөнәри белем бирү оешмаларында (көллиятләрдә);

2 554 кеше – югары уку оешмаларында («Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты» югары һөнәри белем бирү федераль дәүләт мәгариф учреждениесендә – 1 740 кеше һәм «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» югары белем бирү федераль дәүләт бюджет учреждениесендә – 814 кеше).

Мәдәният һәм сәнгать белем бирү оешмаларында
укучылар саны динамикасы

Кадрлар белән тәэмин итү тармакның планлы эше буенча мөһим өлеше, сыйфатлы йомгаклау нәтиҗәсен алу гарантиясе булып тора. Тармакның педагогик хезмәткәрләре саны 4 010 кеше тәшкил итте:

2 943 – өстәмә белем бирү оешмалары укытучылары һәм концертмейстерлары;

731 – һөнәри белем бирү оешмалары укытучылары;

336 – югары уку йортларының профессор-укытучылар составы.

Бүген Татарстан Республикасының сәнгать мәктәпләрендә федераль дәүләт таләпләрен гамәлгә кертү буенча актив эш алып барыла: мәгариф учреждениеләре уставларына үзгәрешләр кертелә, яңа буын белем бирү процессының локаль актлары, уку планнары һәм графиклары эшләнә, лицензияләү узарга әзерләнә.

Урта звено белгечләрен һөнәри белем бирү оешмалары әзерли, аларның максаты – мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә югары квалификацияле, конкуренциягә сәләтле белгечләр әзерләү системасының нәтиҗәлелеген арттыру аша җәмгыятьнең рухи һәм мәдәни кыйммәтләрен саклап калу. Бу миссияне тормышка ашыру укыту-тәрбияләү, фәнни-методик, концерт-башкару һәм агарту эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнештә бара.

Һөнәри белем бирү оешмалары эшенең төп казанышы – студентлар контингентының тотрыклы сакланышы һәм укыту процессында алына торган һөнәри дәрәҗә югары булу. Бу конкурсларда җиңүчеләрнең күп булуы (укучыларның гомуми санының 40 процентка якыны) һәм көллиятне тәмамлаучыларның югары уку йортларына керүләренең тотрыклы югары проценты (32 процент) белән раслана.

Һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары уку йортларын тәмамлаучыларның 70 проценттан артыгы алган белгечлеге буенча мәдәният оешмасында һәм төрле предприятиеләрдә эшкә урнаша.

Мәдәният өлкәсендәге һөнәри белем бирү оешмаларында һөнәрләр һәм белгечлекләр буенча укыту эш бирүчеләр: театрлар, балалар сәнгать мәктәпләре, республика муниципаль берәмлекләренең мәдәният идарәләре, шулай ук зур предприятиеләр белән, шул исәптән «Алмаз Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, «Казан көмеше» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (Казан халык сәнгать һөнәрләре техникумы практикасы) белән тыгыз бәйләнештә алып барыла.

Республика сәнгать белеме системасының сизелерлек уңышларына һәм тотрыклы югары дәрәҗәдә эшләвенә карамастан, аның эшчәнлегендә кимчелекләр дә бар, аларга түбәндәгеләр керә:

уку биналарының торышы тиешенчә булмау;

учреждениеләрнең матди-техник базасы начар булу: уку процессының техник тәэмин ителеше түбән булу (аудио, видеотехника саны җитәрлек булмау), соңгы елларда китапханә фондларын укыту һәм махсус әдәбият белән комплектлау җитәрлек булмау, музыкаль инструментлар паркы таушалу;

кадрлар персоналы картаю;

Казан шәһәрендә спорт заллары һәм тулай тораклар булмау;

урта һөнәри белем бирүнең кайбер белгечлекләренә кабул иткәндә конкурс ситуациясе булмау.

Шулай итеп, карала торган проблемаларны хәл итү системалы якын килүне һәм максатчан программа ысулларын файдалануны таләп итә. Республикада яшәүче һәр кешенең белем бирү хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалана алуына конституциячел хокукларын тәэмин итү, шулай ук белем бирү хезмәтләренең югары

сыйфатын тәэмин итү зарурлыгы 6 нчы ярдәмче программаны эшләүнең мөһимлеген билгели.

SWOT-анализ

| Көчле яклары | Йомшак яклары |
|---|---|
| Үз илебезнең сәнгати-эстетик белем бирү традицияләре бай булу;<br>төрле дәрәҗәдәге мәгариф оешмаларының тулы челтәре булу;<br>тәҗрибәле кадрлар персоналы булу | Мәгариф оешмаларының матди-техник базасы зәгыйфь булу, физик яктан таушалган һәм мораль яктан искергән җиһазлар, техник чаралар, музыка кораллары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителмәү;<br>балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслап бетермәү;<br>кадрлар потенциалы картаю;<br>Казан шәһәрендә тулай торак булмау |
| Мөмкинлекләр | Куркынычлар янау |
| Бюджеттан тыш финанслау чыганакларын җәлеп итү;<br>мәгариф оешмалары проектларына грант ярдәме алуга конкурсларда катнашу | Хезмәт хакы түбән булу сәбәпле, яшь кадрлар китү;<br>балалар сәнгать мәктәпләренең уку-укыту программалары юнәлеше гомумэстетик үстерү ягына үзгәрү сәбәпле, өч звенолы белем бирү чылбыры өзелү;<br>һөнәри белем бирү оешмаларына кабул иткәндә керүчеләр саны җитмәү»; |

6 нчы ярдәмче программаның II бүлегендәге сигезенче абзацында «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

6 нчы ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 6 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

6 нчы ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 344 436,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2014 ел – 328 570,6 мең сум;
2015 ел – 4 006,9 мең сум;
2016 ел – 2 896,9 мең сум;
2017 ел – 3 030,3 мең сум;
2018 ел – 2 836,4 мең сум;
2019 ел – 1 752,8 мең сум;
2020 ел – 1 342,9 мең сум.

6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.»;

6 нчы ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«Халык иҗатына ярдәм итү. 2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасының төп халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын саклап калу, торгызу һәм популярлаштыру» ярдәмче программасында (алга таба – 7 нче ярдәмче программа):

7 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr>
<td>«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td>
<td>7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 649 416,6 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 1 108 788,8 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 540 627,8 мең сум.
<table>
<tr><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум</th></tr>
<tr><th>Татарстан Республикасы бюджеты</th><th>федераль бюджет</th></tr>
<tr><td>2014</td><td>37 278,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>38 162,4</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>40 303,0</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>62 350,5</td><td>6 700,0</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>61 170,5</td><td>6 800,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>89 141,2</td><td>32 764,9</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>95 875,1</td><td>69 048,6</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>173 676,3</td><td>140 960,2</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>232 247,6</td><td>238 709,5</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>105 396,8</td><td>45 644,6</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>86 578,7</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>86 608,7</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>1 108 788,8</td><td>540 627,8</td></tr>
</table>
Искәрмә: 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш»;</td>
</tr>
</table>

7 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең
гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Матди булмаган мәдәни мирас – традицион мәдәниятнең кыйммәтле үзәге. Татарстан Республикасы җирле халыкларының матди булмаган мәдәни мирасын актуальләштерү һәм өйрәнү республика территориясендә яшәүче һәр халыкның мәдәни тиңдәшлеген саклап калу, мәдәниара диалогка ярдәм итү өчен кирәк.

«Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр кертү һәм традицияләрне саклап калу буенча ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе (алга таба – Татарстан мәдәният ресурс үзәге) республиканың матди булмаган мәдәни мирасны саклап калу, популярлаштыру һәм торгызу белән бәйле барлык мәдәни-ял итү учреждениеләренең эшчәнлеген координацияли, матди булмаган мәдәни мирас объектларын мониторинглау буенча эш алып бара, Zoom платформасында «түгәрәк өстәлләр» консультацияләр үткәрә.

2020 елда фестиваль акциясе – Бөтенроссия иҗат коллективлары фестивале (Мәскәү шәһәре) кысаларында Татарстан Республикасының «Боз озату» («Боз озату») йолалары, «Шыйлык» һәм «Карга боткасы» яңгырын уяту йолалары тәкъдим ителгән матди булмаган мәдәни мирас объектлары презентациясе үткәрелде. Шулай ук Матди булмаган мәдәни мирасның федераль каталогына түбәндәге объектларның паспортлары җибәрелде: «Казан татарларының туй йоласы», «Бишек турындагы мифоритуаль күзаллаулар», «Исем бирү йоласы» һәм «Сабантуй».

Традицион халык культурасын өйрәнү максаты белән Татарстан мәдәният ресурс үзәге хезмәткәрләре республика районнарына комплекслы фольклор-этнографик экспедицияләргә баруны дәвам итә. Экспедиция төркеме түбәндәге темалар буенча фәнни-тикшеренү эшләрен алып бара: мифология һәм йола культурасы, балалар фольклоры, бию традициясе һәм музыкаль фольклор. 2020 елда Татарстан мәдәният ресурс үзәге «Халык һөнәрләре техникасы һәм технологияләре» юнәлеше буенча эшне көчәйтте. Үзәк белгечләре тарафыннан алтын тегү техникасы һәм технологияләре буенча мастер-классларга, кизү, металл, агачны нәфис эшкәртү буенча һөнәри видеога төшерүләр үткәрелде. Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләре осталары һәм балалар сәнгать мәктәпләре укытучылары өчен Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә «Татарстанның декоратив-гамәли сәнгате: традицияләр һәм инновацияләр» уку семинары үткәрелде.

2020 елда «Татарстан Республикасының матди булмаган мәдәни мирас объектлары реестры» мәгълүмати электрон системасының техник биреме эшләнде һәм Татарстан Республикасының матди булмаган мәдәни мирас объектларын системага, системага салу, саклап калу буенча максатчан эш алып барыла.

Татарстан Республикасында Россиянең күпмилләтле мәдәниятенең уникаль күренеше буларак халык бәйрәмнәрен һәм фестивальләрен саклап калуга һәм популярлаштыруга аерым игътибар бирелә. 2020 елда «Сабантуй» татар халык бәйрәме, «Каравон» рус фольклор бәйрәме, «Уяв» чуаш мәдәнияте бәйрәме, «Учук» чуаш фестивале, «Гырон быдтон» удмурт мәдәнияте, «Балтай» мордва мәдәнияте, «Иван Купала» славян мәдәнияте, «Семык» мари мәдәнияте, «Питрау» керәшен мәдәнияте, «Түгәрәк уен» Бөтенроссия татар фольклоры фестивале онлайн

форматында үткәрелде, алар бәйрәмнәр тарихы һәм традицияләре турында видеоматериаллар, халык иҗаты буенча мастер-класслар, фольклор коллективлары чыгышларын үз эченә алды.

2020 елда матди булмаган мәдәни мирасны саклап калу буенча яңа проект булып республика территориясендә яшәүче барлык халыкларның традицион уен мәдәнияте аша үсеп килүче буын арасында яңа креативларны тикшерә торган «Uen Fest» балалар уеннары фестивале булды. Бу проектны хәтта балаларны җәмгыятькә җайлаштыруның ниндидер социомобиль мәйданчыгы дип тә карарга мөмкин. Фестивальгә республиканың барлык театр җәмәгатьчелеге, Казан дәүләт мәдәният институты студентлары, муниципаль мәдәният учреждениеләре хезмәткәрләре кушылды. Барлык белгечләр видеога балачактан яраткан уеннар кагыйдәләренең тәфсилле инструкцияләрен яздырган һәм аларны үзләренең социаль челтәрләр битләрендә #уенфест, шулай ук UEN FEST фестиваленең махсус битендә куйган. Саф һавада массакүләм чаралар уздыруга чикләүләр бетерелү белән, артист-волонтерлар Казан ишегалларында балаларга ата-аналарының, әби-бабаларының традицион уеннарына һәм күңел ачуларына кушылу тәкъдиме ясалды. 2020 елның 1 августыннан социаль челтәрләрдә «Үз командаңны күрсәт, һәм без сезгә киләчәкбез!» онлайн марафоны старт алды, аның кысаларында барлык теләүчеләргә видеога язарга һәм яраткан халык уены белән ролик урнаштырырга тәкъдим ителә. 2021 елда «Uen Fest» конкурс өлеше узачак, анда 30 иң яхшы ролик билгеләнәчәк, кавторлары финал шоуына чакырылачак. Күңел ачу өлешеннән тыш, проект шулай ук тәрбия мәсьәләләрен күтәрә. Педагоглар һәм психологлар белән мастер-класслар оештырылды, алар үсеп килүче буынның тәрбияви процессындагы уеннарның роле турында сөйләделәр. 2020 елның декабрь аена кадәр фестивальне оештыру вакытыннан алып, ишегалдында 1 841 уен тамашасы оештырылды, «Uen Fest»ны YouTube каналында рәсми аккаунтларда караулар саны – 1 200, #фестконкурс – 340 950.

Татар халкының традицион костюмын тегүнең традицион технологияләрен саклау буенча «Алтын хәситә» халыкара конкурсын уздыру мөһим проект булып тора. Проектның максаты – җәмәгатьчелекнең мәдәни мирасны саклау механизмы буларак төрле халыкларның милли мәдәниятенә кызыксынуын булдыру, Татарстан Республикасы территориясендә милли костюмның иң яхшы үрнәкләрен күпләп җитештерү индустриясенә кертү формаларын һәм ысулларын эзләү.

«Алтын хәситә» конкурсы кием-салым дизайны, иҗади элемтәләрне киңәйтү һәм ныгыту өлкәсендә белгечләрнең көчләрен берләштерү мөмкинлеге бирә, милли мода индустриясендә яңа чишелешләр һәм яшь белгечләрнең тәҗрибәләрен алмашу һәм аларның һөнәри осталыгын күтәрү өчен мәйданчык булып тора.

2020 елда конкурста катнашуга иҗади коллективлар, хосусый остаханәләр, һөнәрчелек йортлары, мода театрлары, шулай ук мәгариф оешмаларының иҗади белгечлекләре буенча индивидуаль осталар, рәссам-модельерлар, укучылар һәм педагоглардан 128 заявка алынды. Конкурста катнашучылар арасында дүрт чит ил – Германия, Казахстан, Нидерланд һәм Үзбәкстан вәкилләре бар иде. Катнашучылар арасында иң популяр номинация – «Кэжуал (Casual) стиле» заманча авторлык костюмы.»;

7 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 7 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

7 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 1 649 416,6 мең сум тәшкил итә, шулардан Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 1 108 788,8 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 540 627,8 мең сум.

| Ел | Күздә тотыла торган акча күләме, мең сум | |
|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы Татарстан | федераль бюджет |
| 2014 | 37 278,0 | - |
| 2015 | 38 162,4 | - |
| 2016 | 40 303,0 | - |
| 2017 | 62 350,5 | 6 700,0 |
| 2018 | 61 170,5 | 6 800,0 |
| 2019 | 89 141,2 | 32 764,9 |
| 2020 | 95 875,1 | 69 048,6 |
| 2021 | 173 676,3 | 140 960,2 |
| 2022 | 232 247,6 | 238 709,5 |
| 2023 | 105 396,8 | 45 644,6 |
| 2024 | 86 578,7 | - |
| 2025 | 86 608,7 | - |
| Барлыгы | 1 108 788,8 | 540 627,8 |

7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.»;

7 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 8 нче ярдәмче программа):

исемендә «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

8 нче ярдәмче программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

«8 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру сроклары» юлында «2014 – 2025» саннарын «2014 – 2020» саннарына алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 8 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 8 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 8 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 66 237,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 ел – 8 665,9 мең сум;<br>2015 ел – 6 816,8 мең сум;<br>2016 ел – 7 129,6 мең сум;<br>2017 ел – 7 800,1 мең сум;<br>2018 ел – 13 326,9 мең сум;<br>2019 ел – 14 443,2 мең сум;<br>2020 ел – 8 054,5 мең сум.<br>Искәрмә: 8 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда төгәенләнергә тиеш»; |

«8 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «8 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 8 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләрне арттыруга мөмкинлек бирәчәк:<br>гражданнар электрон рәвештә карау өчен мөмкин булган традицион халык мәдәнияте ядкарьләренең чагыштырма авырлыгы 86 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасының юкка чыккан халык кәсепләренең ачыкланган төрләре саны 16 берәмлеккә кадәр;<br>җитештерелә торган продукция номенклатурасын 70 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләрен һәм сувенир продукция сату күләмен 35 берәмлеккә кадәр»; |

8 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 8 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсенең гомуми тасвирнамәсе, шул исәптән хәл итүгә юнәлдерелгән мәсьәләләр

Халык сәнгать һөнәрләре илебез мәдәниятенең, рухи мирасның уникаль өлеше булып тора, ул Россия Федерациясе халыкларының халык иҗатының аерылгысыз байлыгы һәм формаларының берсе булып тора.

Россия Федерациясенең традицион халык культурасы өлеше буларак халык сәнгать һөнәрләрен саклау һәм үстерү өлкәсендә дәүләт сәясәте хәзерге Россия җәмгыятенең тотрыклы үсеше стратегиясенең төп факторы булып тора. Халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу һәм үстерү дәүләтнең стратегик мәнфәгатьләре яссылыгында, бигрәк тә базар шартларында җитештерүнең әлеге үзенчәлекле тармагын саклау һәм үстерү өлешендәята һәм дәүләт өчен мөһим бурыч булып тора.

Халык сәнгать һөнәрләре тармагында көнүзәк проблемаларны хәл итү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәте 1990 нчы еллар уртасында гына чаралар күрде, шуннан соң тиешле закон базасы сизелерлек киңәйде. 1999 елда «Халык сәнгать һөнәрләре турында» Федераль закон кабул ителде, федераль дәрәҗәдә халык кәсепләре проблемалары белән шөгыльләнүче «Россиянең халык сәнгать кәсепләре» ассоциациясе оештырылды.

Әлеге закон белән халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә дәүләт сәясәте нигезләре билгеләнде һәм дәүләт хакимиятенең федераль һәм төбәк органнары арасында вәкаләтләр бүленде. Дәүләт хакимиятенең федераль органнары халык сәнгать һөнәрләре оешмаларын саклап калу, торгызу һәм үстерү өчен икътисадый, социаль һәм башка шартлар тәэмин итә, аларның исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләтләр бирелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан раслана.

Халык сәнгать һөнәрләрен саклау һәм үстерү проблемаларына Россия Федерациясе закон чыгару хакимияте органнары соңгы вакытта ешрак мөрәҗәгать итсә дә, шуны билгеләп үтәргә кирәк: соңгы елларда кабул ителгән чаралар федераль, төбәк һәм җирле дәрәҗәләрдә сәнгать һөнәрләренә законнар чыгару, оештыру һәм финанс ярдәм күрсәтү буенча тулаем алганда әлеге мәдәни эшчәнлекнең тотрыклы төре закон чыгару һәм матди базасы булуын әйтергә нигез бирми. Халык сәнгать кәсепләренең күп өлеше авыр хәлдә булуның төп сәбәпләренең берсе – бу өлкәдә тупланган проблемаларга системалы якын килмәү.

2020 елда халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте грантларын алу конкурсына 28 гариза кабул ителде, гомуми суммасы 5,0 млн.сумга 12 проект хупланды.

Халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мастерларга һәм оешмаларга түләүсез нигездә республика һәм гомумроссия масштабындагы әһәмиятле чараларда, шулай ук республика, бөтенроссия һәм халыкара сәүдә күргәзмәләрендә катнашу хокукы бирелә, бу продукцияне тышкы базарга чыгаруга һәм республиканың мәдәни мирасын популярлаштыруга ярдәм итә.

Татарстан мәдәният ресурс үзәге тарафыннан Татарстан Республикасының авыл районнарында халык һөнәрләрен һәм кәсепләрен, осталар һәм һөнәрчеләр эшчәнлеген саклап калуга һәм үстерүгә ярдәм чараларын күрсәтү эшләре алып барыла.

Бүгенге көндә Татарстан Республикасында халык сәнгать һөнәрләренең түбәндәге традицион төрләре бар:

| Җитештерү төрләре | Халык сәнгать һөнәрләре эшләнмәләре төркемнәре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Күнне сәнгатьчә эшкәртү | Күн мозаикасы; мех мозаикасы; бизәк төшерү, чигү, мозаика белән күн эшләнмәләре |
| Халык сәнгать һөнәрләренең җөй белән чигелгән эшләнмәләрен җитештерү | Тукымалардан һәм башка материаллардан эшләнмәләр; алтын тегү, сәйлән белән чигү; аппликация (элмәкле техника һ.б.) |
| Сәнгатьчә кул тукучылыгы | Декоратив бизәкле тукымалар һәм тукыма эшләнмәләре |
| Сәнгатьчә кулдан эшләнгән челтәр | Кулдан коклюшка белән бәйләнгән челтәр әйберләре (нырта челтәрләре) |
| Агачны һәм башка үсемлек материалларын сәнгатьчә эшкәртү | Агачтан, киселгән, чокып ясалган, гнут белән тегелгән, гнут белән беркетелгән эшләнмәләр; инкрустация; яндыру; яндырып бизәк төшерү, кыйммәтле текстур үзагачтан эшләнмәләр; каен, салам, лозадан үрү техникасы белән эшләнгән эшләнмәләр һәм башкалар. |
| Нәфис керамика җитештерү | Кул белән язып, әвәләп бизәк төшерелгән фаянс, фарфор әйберләр; кул белән әвәләп рәсем төшерү ысулы белән эшләнгән әйберләр, кул белән бизәк төшерелгән башка әйберләр |
| Ювелир әйберләр җитештерү | Көмеш, төсле металл һәм эретмәләрдән, шул исәптән ювелир монтажлау техникасында эшләнгән ярым кыйммәтле кулдан эшләнгән ташлар, филигрань, көзгеләр, эскәмияләр, шулай ук металлны кулдан декоратив эшкәртеп, кою ярдәмендә эшләнгән эшләнмәләр. |
| Сөякне һәм мөгезне нәфис эшкәртү | Йорт һәм кыргый хайваннарның сөякләреннән һәм мөгезләреннән зур күләмле, рельефлы һәм челтәрле, металл, агач, тире һәм башка материаллар белән беркетү техникасында токарь белән эшкәртелгән эшләнмәләр |
| Нәфис келәм һәм келәм эшләү | Катнаш башкару техникасында йонсыз гобелен келәмнәр |
| Нәфис кул бизәкләре һәм тукыма кисәге | Халык сәнгате традицияләрендә кул белән ирекле бизәк төшерү, кайнар һәм салкын батик, кул белән төшерелгән бизәкле кисәк беркетү техникасында эшләнгән тукыма әйберләре |
| Халык сәнгать һөнәрләре производстволарының башка | Халык сәнгате традицияләрендә башкарылган бисердан эшләнмәләр; чигүнең, тукучылыкның, |

| 1 | 2 |
|---|---|
| төрләре | аппликациянең традицион төрләрен кулланып, кулдан ясалган милли киемле курчаклар; тукыма кисәкләреннән тегелгән эшләнмәләр, милли костюм сәнгате; киез эшләнмәләр, кул һәм машина чигүнең төрле төрләре белән эшләнгән (җөй, алтын тегү, бисер һәм башка материаллар белән чигү) эшләнгән киек әйберләр эшләү |

Әлеге 8 нче ярдәмче программада Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, фәнни-тикшеренү учреждениеләренең, мәгариф учреждениеләренең һәм массакүләм мәгълүмат чараларының әлеге өлкәдә килештерелгән эш максатларында Татарстан Республикасының халык сәнгать һөнәрләрен саклап калу, торгызу, өйрәнү һәм үстерү буенча үзара хезмәттәшлеге регламентын эшләүне күздә тота, бу уңай җәмәгать фикерен формалаштырырга, үсеп килүче буынны тарихны һәм традицион халык культурасын өйрәнү нигезендә тәрбияләүгә, шулай ук дөнья аренасында Татарстан Республикасының уңай имиджын формалаштыруга ярдәм итәчәк.

Хәзерге вакытта халык сәнгать кәсепләренең гамәлдәге төрләрен, шулай ук халык сәнгать һөнәрләренең югалган төрләрен, халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә фәнни публикацияләрнең җитәрлек булмавын комплекслы тикшеренүләр һәм өйрәнү начар һәм системасыз үткәрелә. Аз санлы махсус әдәбияттан гражданнарның абсолют күпчелеге файдалана алмый. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан 1980 елларда бастырылган һәм тарихи-этнографик очерклар булган Татарстан Республикасы халык сәнгать һөнәрләренең кайбер төрләре (татар милли чигеше, татар милли аяк киеме, татар зәркән сәнгате, татар зәркән сәнгате) турында буклетлар күптән инде библиографик сирәк күренеш булды. Һичшиксез, әлеге эшләрне өстәмә һәм киңәйтелгән вариантта яңадан бастырып чыгарырга кирәк.

Россия Федерациясендә һәм аннан читтә Татарстан Республикасының халык сәнгать һөнәрләрен популярлаштыру буенча мәгълүмат сәясәте юк: халык сәнгать һөнәрләре күргәзмәләрен оештыру таркау характерда, бары тик төрле фестивальләрдә, күргәзмәләрдә ияреп эшләнгән бер фактор гына булып тора; Татарстан Республикасының халык сәнгать һөнәрләре турында мәгълүмати-белешмә әдәбияты юк диярлек, Татарстан Республикасының тарихын, мәдәниятен, халык сәнгать һөнәрләре традицияләрен ача торган интернет-сайт юк.

Татарстан Республикасының халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә эшләүче предприятиеләрнең һәм оешмаларның заманча торышын анализлап, түбәндәге төп проблемаларның булуы турында нәтиҗәләр ясарга мөмкин:

предприятиеләрнең авыр финанс-икътисадый хәле һәм производстволарның тотрыксызлыгы;

техник базаның югары физик һәм мораль тузуы;

маркетинг эшчәнлеге булмау, идарә итү түбән дәрәҗәдә булу;

төп сәнгать эшләнмәләренә ихтыяҗ кимү, базарда ялган әйберләр һәм түбән сәнгать дәрәҗәсендәге продукция туплану;

федераль ташламалар һәм преференцияләр алу өчен эшләнмәнең сәнгати абруен тану процедурасы катлаулану һәм кыйммәтләнү (халык сәнгать эшләнмәләре үрнәкләрен территориаль сәнгать-эксперт советларыннан федераль дәрәҗәгә аттестацияләү хокукын күчерү), бу легаль базардан китүгә китерә;

төбәкара дәрәҗәдә дә, халыкара дәрәҗәдә дә сату базарлары үсеш алмау.

Халык сәнгать һөнәрләренең индивидуаль осталарына хас үзенчәлекле проблемалар да бар:

индивидуаль хезмәт характерыннан килеп чыга торган осталарның аерымлыгы һәм шуның белән бәйле бер үк әйберләрне кабатлау;

халык сәнгать һөнәрләре осталарының картаюы һәм сәнгать-стиль үзенчәлекләрен һәм традицияләрен югалту куркынычы.

Шуңа бәйле рәвештә халык сәнгать һөнәрләре өлкәсендә кадрлар әзерләү, әлеге өлкәдә дәвамчанлыкны саклау мәсьәләләре кискен тора. Үзгәрүчән хәзерге шартларда халык сәнгать һөнәрләре буенча укытучыларның белем һәм күнекмәләрен адаптацияләү буенча чаралар күрү зарур.

Халык сәнгать һөнәрләре үсешенә йогынты ясый торган факторларны анализлау гамәлдәге проблемаларны берләштерелгән көчләр һәм осталарның, халык сәнгать һөнәрләре оешмаларының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләре белән хәл итәргә мөмкин булуын күрсәтә. Шул ук вакытта бу процесс дәүләт ярдәменең нәтиҗәлелеге белән билгеләнә, ул халык сәнгать һөнәрләре потенциалын тулырак үстерү өчен уңай шартлар тудырырга тиеш.

